| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ** |
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«02» июнь 2021 с. Тюлячи № 201

Теләче муниципаль районы оешуга 30 ел тулуга багышланган «Моңнар агыла туган җирдә» район халык иҗаты Фестивале турында

Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты мәдәният бүлегенең 2021 елның 21 маендагы 32 номерлы хатын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы оешуга 30 ел тулуга багышланган «Моңнар агыла туган җирдә» район халык иҗаты Фестивален үткәрү турында Нигезләмәне кушымта нигезендә (алга таба - Фестиваль) расларга.
2. Район Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгына (Иксанов Д.С.) әлеге Нигезләмәнең үтәлешен тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«02» 06 2021 № 201
карарына кушымта

**Теләче муниципаль районы оешуга 30 ел тулуга багышланган «Моңнар агыла туган җирдә» район халык иҗаты Фестивален үткәрү турында Нигезләмә**

Теләче муниципаль районы оешуга 30 ел тулуга багышланган «Моңнар агыла туган җирдә» район халык иҗаты Фестивале (алга таба - Фестиваль) Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге, мәгариф бүлеге, яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге белән берлектә үткәрелә.

**1. Фестивальнең максатлары һәм бурычлары**

- сәләтле, талантлы яшьләрне эзләү һәм ачыклау;
- талантлы яшьләрне иҗади тормышка ашыру һәм талантларны үстерүдә ярдәм итү;
- яшь гаиләнең иҗади потенциалын ачу;
- коллективларның һәм яшь башкаручыларның башкару осталыгы репертуарының сәнгать дәрәҗәсен күтәрү;
- туган як тарихын һәм мәдәниятен сәнгать чаралары белән пропагандалау, балаларда, үсмерләрдә һәм яшьләрдә патриотизм, гражданлык һәм кече ватанга мәхәббәт хисләре тәрбияләү;
- коллективларның репертуарында милли гореф-гадәтләрнең дәвамчанлыгын саклап калу;
- иҗтимагый-мәдәни эшчәнлек белгечләре һәм барлык теләүчеләр (ата-аналар, педагоглар һ.б.) өчен халык иҗатының барлык жанрлары буенча мастер-класслар оештыру;
- фестивальдә катнашучылар арасында толерант, конфессияара һәм этник мөнәсәбәтләрне ныгыту;
- туган ягыбызга карата кызыксыну һәм хөрмәт тәрбияләү, якташларыбызның: ТАССР атказанган артисты Таһир Якупов, Татарстан Республикасының атказанган артисты Сөләйман Йосыпов, ТАССР халык артисты Нәфисә Василова, ТАССР халык артисты, композитор Фәрит Хатыйпов, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең халык артисты, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, профессор, Казан мәдәният һәм сәнгать университетының музыка сәнгате факультетының җырлау кафедрасы мөдире Венера Ганиева иҗатларын популярлаштыру.

**2. Фестивальнең оештыру структурасы**

2.1. Фестивальне оештыру һәм уздыру өчен оештыру комитеты (алга таба - оештыру комитеты) төзелә, аның составына Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты вәкилләре керә (Нигезләмәнең 1 номерлы кушымтасы).

2.2. Оештыру комитеты:

- Фестивальнең жюри составын формалаштыра (2 номерлы кушымта);

- фестивальне үткәрүдә техник һәм матди ярдәм күрсәтә;

- фестиваль турында массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат таратуны оештыра, кызыксынган оешмаларга фестиваль үткәрү тәртибе турында мәгълүмат җиткерә;

- фестиваль чараларын үткәрү датасы һәм урыны турында 5 көннән дә соңга калмыйча хәбәр итә.

2.3. Оештыру комитеты әлеге Нигезләмәгә өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертергә хокуклы.

**3. Фестивальне үткәрү шартлары һәм тәртибе**

3.1. Фестиваль 2021 елның октябреннән ноябрьгә кадәр үткәрелә.

Беренче этап – зона этабы (2021 елның октябре) - авыл җирлекләрендә һәм район оешмалары арасында район мәдәният йортында үткәрелә. Беренче этап кысаларында үзешчән сәнгать концертлары, шулай ук декоратив-гамәли сәнгать осталары конкурсы – 2021 елның октябрь-ноябрь айларында (3 номерлы кушымта нигезендә) үткәрелә. Фестивальнең бу этабында районның һәр авыл җирлеге һәм оешмалары, график нигезендә, бер сәгатьтән дә ким булмаган концерт программасын тәкъдим итәләр. Сайлап алу турына кертелгән барлык катнашучылар да, 2021 елның 15 ноябреннән дә соңга калмыйча, конкурсны оештыру комитетыннан чакыру алачак.

Икенче этап – сайлап алу (2021 елның ноябре), район мәдәният йортында зона этаплары финалистлары арасында үткәрелә.

Өченче этап – йомгаклау этабы (2021 елның ноябре), фестиваль җиңүчеләре катнашында Гала-концерт һәм биш яшь категориясе буенча һәр номинациядә дипломнар һәм кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләү булачак. Шулай ук фойеда район тарихын чагылдырган үзешчән авторлар һәм декоратив-гамәли сәнгать осталарының күргәзмәләре оештырылачак. Фестивальнең Гала-концерты датасы фестивальнең оештыру комитеты тарафыннан билгеләнә.

3.2. Фестивальдә катнашучылар чыгыш ясау өчен кирәкле костюмнар һәм реквизитлар әзерли.

3.3. Фестивальдә катнашучылар үз эшләрендә Фестивальнең әлеге Нигезләмәсенә таяна.

3.4. Жюри карары шәрехләнми.

3.5. Фестивальнең барышы массакүләм мәгълүмат чараларында даими яктыртылачак.

3.6. Фестивальнең оештыру комитетына җибәрелгән барлык материаллар кире кайтарылмый.

**4. Фестивальдә катнашучылар**

4.1. Фестивальдә иҗади коллективлар да, 5 яшьтән алып 55 яшькә кадәр һәм аннан да өлкәнрәк, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә яшәүче аерым башкаручылар да, районнан чыккан кешеләр дә катнаша ала. Репертуарларда якташларыбыз Таһир Якупов, Сөләйман Йосыпов, Нәфисә Василова, Фәрит Хатыйпов, Венера Ганиева әсәрләре башкарылырга тиеш.

4.2. Фестивальнең конкурс программасы түбәндәге номинацияләрдән тора:

- «Вокал соло»;
- «Вокаль ансамбльләр»;
- «Гаилә ансамбльләре»;

- «Хореография»;
- «Конферанс»;
- «Нәфис сүз»;
- «Инструменталь жанр»;
- «Вокал-инструменталь жанр»;
- «Иң яхшы видеоролик»;
- «Декоратив-гамәли сәнгать»;
- «Иң яхшы концерт» *(авыл җирлекләре һәм оешмалар арасында аерым).*

4.3. Фестивальдә катнашучылар биш яшь категориясе буенча бүленә:
- 5-10 яшь (балалар өчен);
- 11-16 яшь (яшүсмерләр);
- 17-21 яшь (яшүсмерләр);
- 22-35 яшь (яшьләр);
- 36-56 яшь һәм өлкәнрәк (өлкәннәр).

Вокаль, вокаль-инструменталь ансамбльләрдә катнашучыларның уртача яше исәпкә алына.

**5. «Вокал соло» һәм «Вокаль ансамбльләр» номинациясе**

5.1. Башкаручыларның әсәрләре конкурсантның вокал һәм артистлык осталыгын максималь рәвештә ачарга тиеш. Катнашучы тарафыннан 3 минуттан да артмаган әсәр башкарыла. Туган як турындагы җырларның һәм автор тарафыннан башкарылуы хуплана.

5.2. Фестивальдә катнашучылар үз концертмейстерлары белән, шулай ук «-» югары сыйфатлы фонограмма астында чыгыш ясый алалар. Конкурста башкарыла торган номерның биюе һәм театральләштерелүе хуплана.

5.3. Чыгышларны бәяләү критерийлары:
- башкару осталыгы;
- артистлык һәм сәхнә культурасы;
- музыкаль бизәлеш;
- сәхнә костюмы;
- микрофон белән эшләү;
- сыйфатлы аранжировка (финалга үткән катнашучылар өчен);
- оригинальлек.

**6. «Хореография» номинациясе**

6.1. Фестивальнең конкурс программасына катнашучылар үз теләкләре белән биюләр тәкъдим итә (халык, эстрада, классик, стильләнгән).

6.2. Программа югары сыйфат фонограммасы астында башкарыла.

6.3. Коллектив биюләрне башкарганда катнашучылар 3 пардан да ким булмаска тиеш (конкурста соло биюләр исәпкә алынмый).

6.4. Чыгышларны бәяләү критерийлары:

- башкару осталыгы дәрәҗәсе (башкару техникасы, артистлык, сәнгатьлелек, эмоциональлек);
- бию композициясе (драматургия, сюжетлы уй, хореографик рәсем);
- сәхнә костюмы;
- музыкаль бизәлеш.

## 7. «Конферанс» номинациясе

7.1. Конферансье (яки парлы конферансье) программаның киләсе номерны тәкъдим итә (нәрсә турында һәм ничек сөйләргә - конферансье үзе сайлый).

7.2. Чыгышларны бәяләү критерийлары:

- сәхнә культурасы һәм артистлык;
- сөйләм культурасы;
-дикция;
- юмор;
- материал тапшыруның оригинальлеге.

7.3. Конферансье чыкканда реквизит кулланган очракта, реквизит белән эш җайга салынырга тиеш.

7.4. Башкаручының сәхнә костюмы (конферансье киеме алып баручының чыгу бурычына туры килергә, аның үзенчәлекле «визит карточкасы» булырга, шулай ук аның яшьенә туры килергә тиеш).

## 8. «Нәфис сүз» номинациясе

8.1. Әлеге номинациядә катнашучылар Туган якка багышланган проза, поэзия һ.б. тәкъдим итәләр. Җирле авторларның әсәрләре һәм авторларның башкаруы хуплана.

8.2. Бәяләү критерийлары:

- башкару осталыгы;
- артистлык;
- иректе тавыш яңгырашы;
- сәхнә культурасы (кием-салым, манера, җыелганлык, характер);
- башкарыла торган материалның конкурсантның яшенә һәм индивидуальлегенә туры килүе.

## 9. «Инструменталь жанр» номинациясе

9.1. Фестивальнең конкурс программасы теләсә кайсы әсәрнең, ирекле теманың аерым һәм ансамбль белән башкаруны күздә тота.

9.2. Чыгышларны бәяләү критерийлары:

- әсәрләрне башкару техникасы һәм осталыгы;
- репертуар;
- сәхнә культурасы (костюм, манера);
- оригинальлек.

## 10. «Вокал-инструменталь жанр» номинациясе

10.1. Фестивальнең конкурс программасы теләсә кайсы әсәрнең, ирекле теманың аерым һәм ансамбль белән башкаруны күздә тота.

10.2. Чыгышларны бәяләү критерийлары:

- әсәрләрне башкару техникасы һәм осталыгы;
- репертуар;
- сәхнә культурасы (костюм, манера);
- оригинальлек.

## 11. «Иң яхшы видеоролик» номинациясе

11.1. Бу номинациядә катнашучылар «Туган ягым, Теләче!» темасына тулысынча безнең районны ачучы 5 минуттан артык түгел видео тәкъдим итәргә тиеш.

11.2. Чыгышларны бәяләү критерийлары:

- эш эчтәлеге: идеяләрнең булуы һәм үсеше;
- мәгълүматлылык;
- эшләрнең техник сыйфаты (шул исәптән фото һәм видеоматериаллар сыйфаты);
- музыкаль һәм тавышлы алып бару.

## 12. «Гаилә ансамбльләре» номинациясе

12.1. Фестивальдә район территориясендә яшәүче барлык гаиләләр катнаша ала, алар үзләренең иҗади казанышларын, талантларын, осталыкларын, уйлап табуларын күрсәтә алачак. Әлеге номинациядә катнашучылар 5 минуттан да артмаган видеоролик әзерли алалар. Видеороликта гаилә тормышын һәм көнкүрешен чагылдырырга кирәк (гаилә әгъзаларының Ф.И.А.И. эшчәнлек тарихы, гаилә әгъзаларының мавыгуы, гаилә тормышыннан кызыклы фактлар (йорт хайваннары һәм гаилә әгъзалары), гаилә реликвияләре, гаилә тормышындагы әһәмиятле вакыйгалар, бәйрәмнәр һ.б.).

Бәяләү критерийлары:

- оригинальлек;
- режиссура;
- теманы ачу;
- барлык гаилә әгъзаларының да катнашуы;
- башкару осталыгы.

## 13. «Декоратив-гамәли сәнгать» номинациясе

Фестиваль кысаларында район тарихын чагылдырган үзешчән авторлар һәм декоратив-гамәли сәнгать осталарының күргәзмәләре оештырыла. Халык кәсебе эшләнмәләре, сувенирлар, чигүләр, бизәкле тукучылык, челтәрләр, макрама, бәйләү, үрелмә, керамика, агачка бизәк төшерү, ювелир эшләнмәләр, халык костюмы комплекты тәкъдим ителә ала.

## 14. Катнашучыларны бүләкләү

Жюри карары нигезендә, конкурс финалына үткән конкурсантларга, иң яхшы коллективларга, башкаручыларга. Барлык номинацияләр буенча җиңүчеләргә Теләче муниципаль районының 30 еллыгына багышланган «Моңнар агыла туган җирдә» халык иҗаты фестивале лауреаты һәм дипломы бирелә, дипломнар һәм бүләкләр тапшырыла. Жюри Фестивальдә җиңүчеләргә Гран-при бирү хокукын үз иркендә калдыра.

**Барлык төркем башкаручылар күрсәтелгән кагыйдәләр белән танышырга тиеш.**

«Моңнар агыла туган җирдә»
район халык иҗаты Фестивале
Нигезләмәсенә 1 номерлы
кушымта

**«Моңнар агыла туган җирдә» район халык иҗаты Фестиваленең оештыру комитеты составы**

| | | |
|---|---|---|
| | | Оештыру комитеты рәисе: |
| Гыйниятуллин Д.С. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| | | Оештыру комитеты әгъзалары: |
| Ихсанов Д.С. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы; |
| Карпова Н.В. | - | МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» башлыгы; |
| Ибраһимов З.З. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы; |
| Яхин Р.Р. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының Финанс-бюджет палатасы рәисе; |
| Хуҗин Л.Й. | - | «Татмедиа» АҖ филиалы «Теләче-информ» МҮ директоры (килешү буенча). |

«Моңнар агыла туган җирдә»
район халык иҗаты Фестивале
Нигезләмәсенә 2 номерлы
кушымта

**Состав жюри районного Фестиваля народного творчества**
**«Моңнар агыла туган җирдә»**

Жюри рәисе:

| | | |
|---|---|---|
| Ихсанов Д.С. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы. |

Жюри әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Дәүлиева Р.М. | - | Теләче муниципаль районы «Җирлекара китапханә» МБУ директоры; |
| Нәгимова Ф.М. | - | Теләче муниципаль районы «Район мәдәният йорты» МБУ директоры вазыйфаларын башкаручы; |
| Имамиева Ф.М. | - | Теләче муниципаль районы «Туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе директоры; |
| Туктамышева А.Х. | - | Теләче муниципаль районы «Район мәдәният йорты» МБУ сәнгать җитәкчесе; |
| Поташова А.Б. | - | Теләче муниципаль районы «Район мәдәният йорты» МБУ хормейстеры; |
| Нигъмәтҗанов Ф.Н. | - | «Татмедиа» АҖ филиалы «Теләче-информ» мәгълүмат үзәге корреспонденты (килешү буенча). |

«Моңнар агыла туган җирдә»
район халык иҗаты Фестивале
Нигезләмәсенә 3 номерлы
кушымта

**Фестивальнең 1 этабын уздыру графигы**

| МЯУ, АҖ һәм мәктәпләр исеме | МЯУ һәм мәктәпләрнең җаваплы җитәкчеләре, АҖ яшьләр лидеры | Үткәрү датасы һәм урыны | Авыл җирлегендә концерт оештыру өчен җаваплы мәдәният хезмәткәрләре |
|---|---|---|---|
| Алан АҖ<br>Алан авылы мәктәбе<br>Алан авыл мәдәният йорты<br>Балыклы авыл мәдәният йорты<br>Күкчә авыл клубы | Хәсәнов Б.Н.<br>Гыйбадуллин И.Б.<br>Җамалиева Г.Г.<br>Әхмәтова Г.А.<br>Антонова Р.Х. | 02.10.2021<br>Алан авыл мәдәният йорты | Ибраһимова З.В. |
| Айдар авыл җирлеге<br>Айдар БББМ<br>Айдар авыл мәдәният йорты<br>Субаш авыл клубы | Хаҗиев Р.Р.<br>Фәттахова Р.В.<br>Фәләхова Р.А.<br>Романова Т.А. | 02.10.2021<br>Айдар авыл мәдәният йорты | Туктамышева А.Х. |
| Әбде авыл җирлеге<br>Әбде авыл мәктәбе<br>Әбде авыл мәдәният йорты | Рәхмәтуллин Н.Р.<br>Латыйпова Г.Н.<br>- | 08.10.2021<br>Әбде авыл мәдәният йорты | Ибраһимова З.В. |
| Олы Нырсы авыл җирлеге<br>Олы Нырсы авыл мәктәбе<br>Олы Нырсы авыл мәдәният йорты<br>К. Мирәтәк авыл клубы | Гыйниятов Р.М.<br>Чернов П.А.<br>Хәсәнова З.Т.<br>Галимов Р.Р. | 08.10.2021<br>Олы Нырсы авыл мәдәният йорты | Туктамышева А.Х. |
| Баландыш авыл җирлеге<br>Баландыш ТГББМ<br>Баландыш авыл мәдәният йорты<br>Урта Мишә авыл клубы | Мөхәммәтшин Р.Ш.<br>Хуҗин Ю.Р.<br>Тимербайев И.Ф.<br>Сәгъдиева Ф.М. | 09.10.2021<br>Баландыш авыл мәдәният йорты | Минһаҗев Р.И. |
| Олы Мәтәскә авыл җирлеге<br>Олы Мәтәскә авыл мәктәбе<br>Олы Мәтәскә авыл мәдәният йорты<br>Югары Мәтәскә авыл клубы<br>Ямбулат авыл клубы<br>Лесной поселогы китапханәсе | Вәлиуллин М.А.<br>Сөнгатуллин М.М.<br>Гыйманова Г.Х.<br>Гарипова С.Х.<br>Кәримуллин Ш.В.<br>Вохмина Г.Р. | 09.10.2021<br>Олы Мәтәскә авыл мәдәният йорты | Поташова А.Б. |
| Олы Мишә авыл җирлеге<br>Олы Мишә мәктәбе<br>Олы Мишә авыл мәдәният йорты<br>Яңа Саурыш авыл клубы | Җамалетдинов Ф.Б.<br>Сафин А.С.<br>Муллахмәтова А.А.<br>Хәкимов И.М. | 15.10.2021<br>Олы Мишә авыл мәдәният йорты | Минһаҗев Р.И. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге<br>Кече Кибәхуҗа авыл мәктәбе<br>Олы Кибәхуҗа авыл мәдәният йорты<br>Казаклар авыл клубы | Заһидуллин И.Г.<br>Әхмәтҗанова Н.Н.<br>Хәкимова Р.Б.<br>Мөхәммәдиев М.И. | 15.10.2021<br>Олы Кибәхуҗа авыл мәдәният йорты | Поташова А.Б. |
| Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге<br>Югары Кибәхуҗа авылы мәктәбе<br>Югары Кибәхуҗа авыл мәдәният йорты<br>Максабаш авыл мәдәният йорты | Мәхмүтов Ф.Р.<br>Миңнекәева Г.Г.<br>Низамов И.В.<br>Сөнгатуллина А.А. | 16.10.2021<br>Югары Кибәхуҗа авыл мәдәният йорты | Вәлиуллин И.К. |
| Шәтке авыл җирлеге<br>Шәтке авыл мәктәбе<br>Шәтке авыл мәдәният йорты | Кадыйров Ф.Г.<br>Ибушев А.А.<br>Габдуллина Ф.Н. | 16.10.2021<br>Шәтке авыл мәдәният йорты | Муллахмәтова А.А. |
| Үзәк АҖ<br>Үзәк авыл мәктәбе<br>Шармыш авыл мәктәбе<br>Сауш авыл мәктәбе<br>Үзәк авыл мәдәният йорты<br>Шармыш авыл клубы<br>Сауш авыл мәдәният йорты | Котников В.Н.<br>Николаев А.В.<br>Пашагина С.П.<br>Фазлыева М.Г.<br>Майсурадзе К.В.<br>Тарасова Е.И.<br>- | 23.10.2021<br>Үзәк авыл мәдәният йорты | Муллахмәтова А.А. |
| Иске Җөри авыл җирлеге<br>Иске Җөри авыл мәктәбе<br>Иске Җөри авыл мәдәният йорты<br>Тиләҗе авыл клубы<br>Караширмә авыл клубы | Мараков Р.Р.<br>Назклычев С.С.<br>Насыйбуллин Р.М.<br>Сәхәбиева Р.Р.<br>Мөхәммәдиева А.М. | 23.10.2021<br>Иске Җөри авыл мәдәният йорты | Вәлиуллин И.К. |
| Теләче авыл җирлеге<br>Теләче УГББМ<br>Балалар сәнгать мәктәбе | Мараков И.Р.<br>Хафизов А.Ф.<br>Вәлиева А.Д. | 22.10.2021<br>Район мәдәният йорты | Нәгимова Ф.М. |
| Совет,<br>Башкарма комитет,<br>АХһАТИ, ФБП | Мөбинов И.В.<br>Хәмидуллин И.Х.<br>Низаметдинов Р.Х. | 26.10.2021<br>Район мәдәният йорты | Фатыйхова Л.Г. |
| «АК БАРС» БАНК,<br>«Россельхозбанк»<br>Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге<br>ТР казначылыгы<br>ТР ФМ Федераль казначылык бүлеге | Мортазин Ф.А.<br>Борһанов Ф.Р.<br>Галимҗанов А.М.<br>Нургалиев Ф.С.<br>Закирова Р.Ф. | 27.10.2021<br>Район мәдәният йорты | Галәвиева Ф.Г. |
| «Сабыгаз» эксплуатация-җитештерү идарәсе<br>МҮ «Теләчеинформ» | Хаҗиев Р.М.<br>Хуҗин Л.Й. | 28.10.2021<br>Район мәдәният йорты | Хуҗина Э.Б. |
| Янгын күзәтчелеге бүлеге<br>Янгын бүлеге | Хәкимуллин Л.М.<br>Шәрипов М.М. | 29.10.2021<br>Район мәдәният йорты | Имамиева Ф.М. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Подстанция (РЭЧ) | Якупов Р.Ш. | 30.10.2021<br>Район мәдәният йорты | Абдуллина А.Р. |
| РЭЧТ<br>РПЭИ<br>«РосГосстрах-Татарстан»<br>«Энергосбыт»<br>«Ингосстрах» | Галимуллин Р.Р.<br>Заһидуллин Р.Р.<br>Любовь Г.А.<br>Галәвиев И.Ф.<br>Мортазин Н.Ә. | 03.11.2021<br>Район мәдәният йорты | Касыймов Р.М. |
| Ветеринария берләшмәсе<br>Агрохимсервис<br>ЮИ (юл) | Гарипов И.Г.<br>Хәкимов Л.С.<br>Ярмиев И.З. | 05.11.2021<br>Район мәдәният йорты | Имамиева Ф.М. |
| МКУ «Мәгариф бүлеге»<br>Балалар иҗаты үзәге | Карпова Н.В.<br>Мәхмүтова З.Ш. | 06.11.2021<br>Район мәдәният йорты | Биктимирова Р.Р. |
| ЯЭСhТБ | Ибраhимов З.З. | 10.11.2021<br>Район мәдәният йорты | Нәгимова Ф.М. |
| Пенсия фонды бүлеге<br>Социаль яклау бүлеге | Тимербаева А.А.<br>Галимова Ф.М. | 11.11.2021<br>Район мәдәният йорты | Шәрәфетдинова Л.Н. |
| ДАССУ «Теләче РҮХ»<br>«Ак Барс Мед» | Галиуллин И.И.<br>Галимов Ф.Ф. | 12.11.2021<br>Район мәдәният йорты | Имамиева Д. |
| РОВД,<br>ЮХИДИ бүлеге<br>ДОСААФ | Зарипов И.С.<br>Назиров Р.Х.<br>Нуртдинов Р.Р. | 13.11.2021<br>Район мәдәният йорты | Шәрифуллина Г.Г. |

Тәкъдим ителгән якынча репертуар

Таhир Якуповның репертуары

1. "Сәяхәтче җыры" (З. Гыйбадуллин көе)
2. "Миләүшә" (А. Ключарев көе)
3. "Олы юлның тузаны" (татар халык җыры)
4. "Зөләйха" (татар халык җыры)
5. "Наласа" (татар халык җыры)
6. "Дусларым" (татар халык җыры)
7. "Ай-ли, гөлкәем" (татар халык җыры)

Нәфисә Василова репертуары

1. "Киек казлар" (М. Макаров көе, Х. Туфан сүз.)
2. "Гөлҗамал" (татар халык җыры)
3. "Тәфтиләү" (татар халык җыры)
4. "Беләзегем, йөзегем" (татар халык җыры)
5. "Җидегән чишмә" - татар халык җыры)
6. "Үз илемдә" (татар халык җыры)
7. "Яшьлек эзләре"(татар халык җыры)

Сөләйман Йосыпов репертуары

1. "Жизнәкәй" (татар халык җыры)
2. "Умырзая" (Р. Ибраһимов көе)
3. "Яшәсен кияүләрем" (З. Хабибуллин көе)
4. "Өф-өф итеп" (Р. Еникеева сүз.)
5. "Кәвәл авылы көе" (З. Хабибуллин көе)
6. "Кондырак болыннары" (татар халык җыры)
7. "Җаныем- бәгьрем" (татар халык җыры)

Репертуар Фарита Хатипова

1. "Хаман яратам" (Зөлфәт сүз.)
2. "Авыл кызы" (Д. Хәбибуллин сүз.)
3. "Моңлану" (Ф. Сафин)
4. "Шулай шул" (Р. Миңнуллин сүз.)
5. "Шушы яктан шушы туфрактан без"(К. Булатова сүз.)
6. "Иделкәем" (Ш. Җихангирова сүз.)
7. "Туган ягым Теләче" (А. Сабиров көе)

Репертуар Венеры Ганиевой

1. "Туй күлмәге" (М. Дунаевский)
2. "Кыр казлары" (М.Имашев көе, И. Юзиев сүз.)
3. "Ак пороход" (С. Абдуллин көе, Р. Вәлиев сүз.)
4. "Яратыгыз" (Р. Миңнуллин сүз., Р. Ахиярова көе)
5. "Мин сине шундый сагындым" (Л. Батыр-Болгари көе, Ф. Зыятдинова сүз.)
6. "Талларым" ( З. Сафиуллин көе, Р. Рәкыйпов сүз.)
7. "Зәңгәр кыңгыраулар" (Ф. Әбүбәкеров көе, Ә. Баян сүз.)